ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЫШЛАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КШКЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422008 Республика Татарстан Атнинский район с. Кшклово. Тел. 3-43-45

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» сентябрь 2025 ел. № 11

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 11 апрелендәге 10 номерлы «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында "2025 елның 31 июлендәге 304-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Кышлау авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 11 апрелендәге № 10 карары белән расланган белешмә(өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1. карар преамбуласында** "Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары" сүзләрен «республика башкарма хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга;

**1.2. 2.5.1 пунктының 4 пунктчасында** «мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртү зарур» сүзләрен «мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү зарур" сүзләренә алмаштырырга»;

**1.3. 2.5.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4.1 пунктчасы өстәргә:**

«4.1. Мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси белешмәләре җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча вәкаләтләрен үтәү өчен ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы ярдәмендә бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә мондый белешмәләр күрсәтелмичә, мондый затның яисә аның законлы вәкиленең күрсәтелгән максатларда мондый затның шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгын алу таләп ителми»;

**1.4. Административ регламентның 2.6.3 пунктында** «дәүләт хакимияте органнары» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары» сүзләренә алмаштырырга.;

**1.5. Административ регламентның 2.7.1 пунктының 7 пунктчасында** «дәүләт хакимияте органы," сүзләрен төшереп калдырырга;

**1.6. Административ регламентның 2.8.2 пунктының 2 пунктчасында** «дәүләт хакимияте органнары» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары» сүзләренә, «дәүләт хакимияте органына» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектының башкарма органына» сүзләренә алмаштырырга.;

**1.7. Административ регламентка түбәндәге эчтәлекле 2.8.5 яңа пункт өстәргә:**

«2.8.5 Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарткан очракта, күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтүче органнар, кире кагуга сәбәп булган документлар һәм мәгълүмат исемлеген күрсәтеп, шулай ук федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең туры килмәве муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартуга китергән исемлеген күрсәтеп, мөрәҗәгать итүчегә мондый баш тартуның сәбәпләре турында хәбәр итәләр»;

**1.8. Административ регламентның 5.2 пунктында** «дәүләт хакимияте» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (http://atnya.tatarstan.ru/ ) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Кышлау авыл җирлеге башлыгы: Кашшапов А.Х.